ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ГЫЙНВАР,
2016 нчы ел

№5 (20)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**







**11— Халыкара “РӘХМӘТ” көне**

**25—Студентлар көне**

## «УРА КАНИКУЛЛАР!»

Менә II чирекне дә тәмамладык. Яңа ел бәйрәмнәрен мул табын, бүләкләр һәм кунаклардан башка күз алдына да китереп булмый. Әмма кышкы каникуллар вакытында барлык балалар да кул кушырып утырды дигән сүз түгел. Кайбер укучылар ялларда да белем коесын казу белән мәшгуль булды. Хәзер язга чаклы парта артында түзеп утырырга кирәк, мәктәп укучылары өчен иң озын чирек башланды. Яңа 2016 нчы уку елыннан ук мәктәп коридорларына килеп кергән прогресс-яңалыкларга да иярләшеп өлгерергә кирәк. Кемнәрдер республика олимпиадаларына әзерләнә, кемнәрдер булачак БДИлар турында уйлана башлагандыр. Ә менә чыгарылыш сыйныфта белем алучыларга исә каникул рәхәтен тоярга да вакыт юк. Чөнки алда зур сынау – бердәм дәүләт имтиханнары. Туктап торырга вакыт юк – зур тизлек заманы. Ә син тукталыш ясап алырга өлгерәсең. Рәхим ит! “ Көзге” - бүген синеке!

. **Гөлшат Гайсина**

Бу санда:

Грипп «ишек кага» 2

25 нче гыйнвар— Студентлар көне 3

Якыннан танышыйк! 4

Иң көчлеләр билгеле 5

Көлке хикмәте 6

«Ялкын» җинүчеләре! 6

Котлыйбыз! 7

## *Ял тәэсирләре*

Кышны нәрсә өчен яратып була? Энҗе кар бөртекләре, тәрәзәдәге челтәрле бизәкләр, җылы бияләйләрдән тыш, әлбәттә инде, озы-ы-ын каникуллары өчен! Ә безнең укучыларыбызның яллары ничегрәк үтте икән? Әйдәгез, карап карыйк:.

**Гайшә:** Мин 100% канәгать! Дусларым, туганнарым белән аралаштым. Кышкы матурлык белән ләззәтләнеп, урамнан керәсе килмәгән, ТВ белән генә чикләнгән көннәрем дә булды.

**Илназ**: Авыл клубы оештырган төрле чараларда бик теләп катнаштым, урамда йөрдем.

**Айгөл**: Авылымда да, шәһәрдә дә, туганнарымда да булырга өлгердем.

**Алсу:** Күземә әдәбият китабыннан кала берни дә күренмәде – олимпиадага әзерләндем!

**Рәзилә**: Миндә гап-гади каникул булды! Саф һавада йөрдем, компьютерым белән тагын да ныграк “дуслаштым” һәм, әлбәттә, әти-әниемә ярдәм иттем.

# 11 декабря—Международный день «СПАСИБО»

11 января можно без преувеличения назвать одной из самых «вежливых» дат в году — сегодня отмечается Международный день «спасибо». Все мы прекрасно осознаем значение хороших манер, их необходимость в повседневной жизни, но большую часть благодарностей мы выражаем, как бы невзначай, не задумываясь об их смысле. Однако, слова благодарности обладают магическими свойствами — с их помощью люди дарят радость друг другу, выражают внимание и передают положительные эмоции — то, без чего наша жизнь стала бы скудной и мрачной. Неспроста во многих туристических путеводителях и наставлениях туристам часто указывается: слово «спасибо», произнесенное даже с акцентом на языке страны пребывания, повышает скорость, качество обслуживания и помогает наладить спокойный и приятный отдых.




## ИГЪТИБАР: САЛКЫННАР!!!

Гыйнвар аеның иң суык көннәре азакка калган күрәсен. 26 –27 гыйнварда иң салкын көннәр булды. Шуңа салкыннарда сәламәтлегегезне саклагыз, авырмагыз. Җылы киенеп йөрергә киңәш ителә. Аяк - кулларыгызны өшетмәгез.

**Сәламәт булыйк!**

## Первая помощь при обморожении



В отапливаемом помещении согрейте обмороженную часть тела, растерев ее сухой мягкой тканью. Затем поместите ее в теплую воду, и постепенно доведите температуру воды до 40-45 градусов. Если боль проходит и чувствительность восстанавливается, то вытрите руку (ногу) насухо, наденьте носки (перчатки) и, по возможности, обратитесь к врачу.



**Юнусова Виктория**

## ГРИПП «ишек кага!»

Грипп – эпидемиягә китерә торган инфекция. 9-10 ай эчендә ул җир шарының 30 процент халкын зарарлый ала. А(H1N1) – тагы да көчлерәк эпидемиягә китерә торган А гриппының бер төре. Ул кешеләрне дә, шулай ук күп кенә хайваннарны да зарарларга мөмкин. Бу төр грипп беренче тапкыр 1931 нче елда Америка галиме Ричард Шоуп тарафыннан дуңгызларда табыла. 2009 нчы елның 11 нче июнендә Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы А (H1N1) пандемиясе башлануны хәбәр итә.

Гриппны ничек кисәтергә һәм дәваларга соң? Кисәтүнең иң үзенчәлекле төре – вакцинация. Дәвалау өчен арбидол, интерферон, ремантадин, ингаверин, осельтамевир, терафлю, фервекс кулланыла. Авыруларга постель режимы киңәш ителә. Сөт ризыклары, җиләк-җимеш, яшелчә соклары бирелә, күп итеп җылы чәй, юкә чәчәге, гөлҗимеш төнәтмәсе, компот, мүк җиләге морсы, сөт әчү файдалы була. Өстәмә итеп аскорбин кислотасы билгеләнә. Ачы тәмләткечләр, кыздырылган ризыклар менюдан алына.

**Абдрахманова Рәзилә**

Һәр кышта безне салкын тиюләр сагалап тора. Гадәттә дымлы һавада вируслар көчү өчен уңайлы шартлар туа. Авыруны аяк өстендә үткәрмәгез, авыруның катлауланып китүе бар. Шуның өчен табибка күренергә кирәк һәм халык медицинасына таянып дәвалана аласыз. Кура җиләге, юкә чәчәге, мүк җиләге төнәтмәсе әчәргә киңәш ителә.. Лимон, суган, сарымсакны да читкә куярга түгел.

**Сәламәт булыгыз, үзегезне саклагыз!**

# Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ситдикова Клара Касыйм кызы җавап бирә.**

- Клара Касыймовна, ни өчен Сез укытучы һөнәрен сайладыгыз?

- Бала вакытта ике сеңелемне укыткан-мын. Рус теле укытучысы Флера апа Вәлиуллинага укучыларның дәфтәрләрен тикшерергә булыша идем. Аның тарафыннан бирелгән төпле белем миңа Алабуга дәүләт педагогика университетына укырга керергә мөмкинлек бирде. Укуымны уңышлы гына тәмамлагач, мине юллама белән Фома авылына рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп җибәрделәр.

**- Клара апа мәктәптә 30 ел эшлисез. Мәктәпкә карашыгыз үзгәрмәдеме?**

- Ел саен диярлек үзгәреп торган программалар, дәреслекләр мәктәпкә булган карашны үзгәртә, билгеле. Бик күп кирәкмәгән «кәгазь боткасы» укытучының никадәр балалар белән эшләү вакытын урлый. Шулай ук БДИ, ЕГЭлар да, 4нче сыйныфта үткәрелүче мониторинг та мәктәпне ниндидер куркыныч урын итеп күрсәтә башлады. Бигрәк тә бу эти-әниләр карашында сизелә.

**- Хәзерге балалар Сезнең замандагы балалардан аерыламы?**

— И-и, нинди аерылмаган?! Без башлангыч сыйныфта укыганда укытучы апалар коридорда сөйләшеп торсалар, анда чыгарга

Тагын шунысы күңелне бик борчый: хәзерге укучы балаларның күбесендә хөрмәтләү юк. Гади генә әйбер — күбесе исәнләшми! Әбезнең чор балалары мәктәптә генә түгел, урамда әллә ничә очраса да, укытучы белән исәнләшмичә китми идек. Бар, бик матур итеп исәнләшеп йөрүче балалар да бар... Әмма алар сирәк

**— Клара апа, Сезнең озын тормышыгызда иң бәхетле көнегез нинди?**

— Хәзергә һәр көнем бәхетле.

**— Газета укучыларыбызга теләкләрегез?**

— Әни буларак теләгем: балалар исән-имин, таза-сау, бәхетле бул-

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**

# 25 нче гыйнвар — Студентлар көне




1755 нче елның 25 нче гыйнварь көнне императрица Елизавета Петровна "Мәскәүдә Университет һәм ике гимназия ачу Указына" кул куйган. Шуннан соң 25 гыйнвар официаль университет һәм студент көне дип санала. Хәзерге вакытта да Россия студентлары, концертлар куеп, төрле конкурслар ясап, үз бәйрәмнәрен гөрләтеп үткәрәләр. Чөнки студент тормышы – иң күңелле чак, дип әйтергә мөмкин. Һәрбер кешенең хәтерендә бу вакытлар төрле яклары белән истә кала. Кеше гомерендә кызыклы, күңелле, беркайчан да онытылмаслык вакыйгалар, чаралар бик күп була. Ә иң истә калганнары студент тормышы белән бәйледер, миңа калса.

Яшь, чибәр, уңган-булган, бер урында тик тора белмәгән, юмор хисенә бай, юк-бардан кызык ясый белә торган, иртән беренче дәресләргә йоклап калган вакытлары булган, «әни ашлары»н сагынучы, декабрь һәм июнь айларын «зарыгып» көтүче һәм башка бик күп сыйфатларга бай булган кем дисезме? Әйе, әйе, студент, сез бер дә ялгышмыйсыз!

Барлык студентларны бәйрәмнәре белән КОТЛЫЙБЫЗ!

**Хайбуллина Алсу**



# Яшь каләм тирбәтүчеләр!

**Кул кулны юа, ике кул битне юа**

Борын-борын заманда яшәгән, ди, булган, ди, бер Кеше. Эшләп арыганнан соң, ял итәргә яткан да йокыга да киткән, ди, үзе. Менә берзаман бу Кешенең Уң кулы белән Сул кулы бәхәскә кергән. Ә Кеше шулкадәр тирән йоклый, ди, хәтта кулларының кычкырышканнарын да ишетмәгән.

Мин барлык эшләрне дә үзем эшлим. Хуҗага мин генә кирәк, ә син аңа авырлык ясап салынып кына йөрисең! – дигән Уң кул.

Син нәрсә сөйлисең? Коедан су тартканда, чиләктән су агызганда миннән башка нишләр идең? Утын ярганда да мин кирәк. Ә кәстрүл кебек әйберләрне миннән башка күтәрә алыр идеңме әллә?

Ә бит барлык эшләрдә дә мин башлап йөрим, син шунда ияреп кенә йөрисең!- дип мыскыл иткән һаман аны Уң кул. Әллә тавыш тәэсир иткәнме, Кеше әйләнеп яткан һәм Уң кул хуҗаның астында калган.

Ярый, иртәгә хуҗа ауга бара, син генә барырсың, мин ияреп йөрмәм. Үзең генә мылтыктан төз ата алырсың микән, карарбыз, - дип җавап биргән Сул кул.

Хуҗа астында калган булса да, ысылдап җавап биргән Уң кул.

Әй, куркытты, ди, берәү! Син бит кашык тотарга да ярамыйсың. Кешеләр дә “Сул кул белән ашау - гөнаһ”, дип саныйлар. Син бәдрәфтә генә башлап йөрисең! – дип ярсыган ул.

Сул кул аны сабыр гына тыңлап торган да:

Әйе, аны кешеләр, тәртип булсын өчен, кагыйдә итеп уйлап чыгарганнар. Синең бәхетеңә кашык, ипи тоту эләккән. Язмыштан узмыш юк. Өлешеңә тигән көмешең инде. Ә бит калган эшләрне без бердәй тигез башкарабыз, - дигән.

Хуҗа астында калган Уң кул оеган, көзән җыеруга түзә алмыйча Сул күршесен ярдәмгә чакырган.

Әй, тартып чыгар әле мине моннан, авырта, түзәлмим, - дигән ул. Ә Сул кул урыныннан да кымшанмаган.

Син нәрсә, минем буталып, комачаулап йөрергә хакым юк, хуҗага да кирәкле түгел бит мин, - дигән. Уң кул хаталанганлыгына төшенә башлаган. Ниһаять, җайсыз ятудан арып, Кеше сикереп торган һәм, үзе дә сизмәстән, Сул кулы белән Уңын ышкырга тотынган. Шуннан соң Уң кул үзен уңай сизә башлаган. Шуннан Кеше юынгыч янына килгән һәм ике кулы белән битен юган.

Әһә, - дигән Уң кул хатасын аңлап.- Кул кулны юа, ике кул битне юа икән ләбаса! Димәк, һәрчак дус булырга, ярдәмләшеп яшәргә кирәк икән. Шул көннән башлап, Кешенең куллары тату гомер кичергәннәр, ә Уң кул әйткән сүзне халык мәкаль буларак куллана башлаган.

28 нче гыйнвар көнне Нурлат шәһәренең 9 нчы мәктәбендә укучыларыбыз **Хайбуллина Алсу, Шакурова Алсу, Әһлиуллин Аяз, Гайсина Гөлшат “Мин—Россия гражданины”** дип исемләнгән социаль проектлар бәйгесендә чыгыш ясап кайттылар.







## Олимпиада — тырыш һәм сәләтлеләр бәйгесе

Ниһаять, район олимпиадалары да тәмамланды. Безнең мәктәп укучылары да үзләрен тиешле дәрәҗәдә күрсәтте . Татар теле һәм татар әдәбиятыннан 2 призлы урын! Ә иң күңеллесе, район күләмендә БЕРЕНЧЕ урын бездә бит! Афәрин! Республика күләмендә дә укучыларыбыз Шарапова Ләйсән , Гафурова Алия сынатмаслар. Районыбыз данын яклаган кызларыбызга ныклы сәламәтлек, яңа уңышлар теләп калабыз!

# *Көлке хикмәте*



*****

Берәү самолетка сарык алып кермәкче була икән. Стюардесса:

- Самолетка сарык белән ярамый.
- Бу сарык түгел, күчтәнәч, ә сарык Казанда экзамен бирә.

****

Җәй көне Алла Бабай белән, Күкри бабай ил буенча йөриләр икән, кемгә яңгыр бирергә, кемгә юк икәнен ачыклап.

Бер төбәккә җитәләр. Күкри:

- Боларга бирикме?
- Әйдә...

Икенчесенә җитәләр.

- Боларга?
- Бирик...

Татарстанга җитәләр.

- Боларга бирикме?
- Юк, алар үзләре дә БУЛДЫРА!

****Автобуста:

- Билетың бармы?
- Ә синеке.
- Синең билет?
- Минем билет?
- Син авыру мәллә?
- Ә син табиб мәллә?
- Әйдә, синең билет?
- Әйдә. Минем билет.
- Нәрсә ,башка сүзләр белмисең мәллә?
- Беләм, катыргы.
- Энем, мин контролёр!
- Апай, мин сантехник...
- Сезнең барысы да өйдәме соң???
- Кунакка киләсез мәллә?..
- Әйдә, синең билет!
- Әйдә. Минем билет
- Син нәрсә - куян?
- Син нәрсә - бүре?
- Билетын бармы дим!!!
- Нәрсәгә соң ул сиңа?
- Карарга...
- Сатып ал да кара...
- Синең билет!
- Минем билет. Ә менә монысы - минем тукталыш!

# Хоккей— чын егетләр уены

30 нчы гыйнвар көнне Кизләү урта мәктәбендә **Татарстанның атказанган укытучысы, Н.К.Крупская исемендәге премия лауреаты Ф. С. Хаметовның** якты истәлегенә багышланган хоккей ярышлары үтте. Егетләребез : **Мингалимов Илнар, Замалеев Алмаз, Зиннуров Рәзил, Шагиахметов Илназ, Садртдинов Айдар, Закиров Рәзил, Мингалимов Нәфис, Гилязов Әлфис** физкультура укытучысы **Замалеев Айрат Каимович** җитәкчелегендә 1 нче урынны яулап кайттылар. Уенчыларыбыз ярыштан матур тәэсирләр белән кайтты. "Иң яхшы капкачы" номинациясендә җиңүгә исә безнең мәктәп командасыннан Зиннуров Рәзил лаек дип табылган. Афәрин! Без сезнең белән горурланабыз, егетләр. Бу ярыш - алдагы зур җиңүләр алдыннан реванш алу булсын!

**Таһирова Гайшә**





## БДИ: үзгәрешләр дәвам итә

Бердәм дәүләт имтиханында “кыек атып, туры тидерү” мөмкинлеген киметә баралар. Ягъни белмичә генә очраклы рәвештә дөрес җавап бирермен дип ышанып, сынауга килеп булмаячак. Инде узган елда ук кайбер фәннәрнең беремнәрендә тест өлеше юкка чыгарылды. Быел да бу процесс дәвам итәчәк. Укучыларның белем сыйфатына шул очракта гына дөрес бәя биреп булачак дип санала. 2016 нчы елда бердәм дәүләт имтиханын 17 мең чыгарылыш сыйныф укучысы тапшырыр дип көтелә.

**БДИ да укучылар тупларга тиешле минималь баллар күләме узган елдагы кебек кала. Укучыларга рус теленнән, ким дигәндә – 36 , профиль дәрәҗәдәге математикадан – 27, физика, химия һәм биологиядән -3 6, информатика һәм мәгълүмати – коммуникацион технологияләр буенча иң ким – 40, тарихтан һәм рус әдәбиятыннан – 32, географиядән – 37, җәмгыять белеменнән – 42, чит телләрдән 22 балл җыярга кирәк.**

**Бердәм дәүләт имтиханының төп дулкыны 26 нчы майдан 30 нчы июньгә кадәр узар дип көтелә.**



Мәктәбебезнең 7 нче сыйныф укучылары һәм аларның сыйныф җитәкчесе Гөлүсә Әһлиуллина “Ялкын” журналы уку елы башында игълан иткән **“Укытучыларның сәләтен ачабыз!”** конкурсында катнашып , җиңүче исеменә лаек булды. Укучыларыбыз әлеге конкурста **“Безнең сыйныф җитәкчебез”** дип аталган видеоэш белән катнашып, анда үзләренең сыйныф җитәкчеләре Гөлүсә Дамир кызы турында сөйләделәр. Яңа җиңүләреннән рухланган җиденчеләр исә бу көннәрдә яхшы кәеф белән яңадан – яңа конкурсларга әзерләнә.

## «Ялкын» җиңүчеләре

**Рузиля**.Беләсезме, сизәсезме,
Без кемгә гашыйк булдык?
Сыйныф җитәкчебездән без
Бигрәкләр инде уңдык.
**Аяз**.Безнең апабыз - Гөлүсә,
Гөл булып үсә, димәк.
Сыйныфыбызның кояшы -
Ул барыбызга кирәк.
3. **Гөлшат**.Гөл нурыннан күз камаша,
Хуш исен җаным сөя.
Гөлдәй гүзәл, мәрхәмәтле
Апага: “Рәхмәт!”- диям.
4.**Илназ**.Төрле гөлләр сыйфатына
Укытучыбыз ия:
Канәферләр кебек төгәл,
Вакыт кадерен белә,
5.**Гайшә**.Лаләдәй янарыш сөя,
Мәтрүшкәдәй дәвалый,
Роза күк ярата белә,
Кыңгыраулардай җырлый.
6.**Илнар.** Кашкарыйлар кебек озак
Эшлә мәктәптә, апа!
Сабыр, түзем, көчле бул да
Син безне һәрчак якла!
7.**Алинә**. Рәхмәт, апа, сингапурча
Дәрестә такылдыйсың!
ДИАны оныттырмыйсың,
Алка да тактырмыйсың.
8. **Рузилә**.Заман белән бергә атлап,
Яшәргә җитә көчең!
Юк синең белмәгән эшең,
Зур рәхмәт барысы өчен!
**Зур рәхмәт сиңа, апа, мең рәхмәт!**
**Безнең мәктәптә укуы рәхәт!**
1.**Вика**.Тузган чәчне үрдерткәнгә,
Тырнак буятмаганга,
Өй эшләрен күчерүне
Хәтта уйлатмаганга
2.**Әлфис**.Рәхмәт, апа.Бергә кызык,
Төркемләп утырабыз.
ФДББС – янача
Укырга булдырабыз.
3.**Адилә**.Үзебез бик гади халык,
Кәбестә күк бер катлы.
Ападан качып киттек тә
Алда күреп шаккаттык.
4.**Рәмис.**Юкса безгә күп кирәкми,
Җитә булса интернет.
Рәхмәт, апа, утырабыз
Китап укып, интегеп.
5. **Рәзилә.**Рәхәт, уннан соң рөхсәт юк
Кичке һава суларга,
Имеш, төнлә чыгалар тик
Акбай кебек уларга.
6. **Аяз.** Дискотека яратабыз,
Тиктормаслар үзебез.
Апа бездән дә уздыра,
Җитми мактау сүзебез.
7. **Рузиля**. Швейцария банкы кебек
Ышанычлы апабыз.
Икенче әниебезне
Без бик-бик яратабыз!
**8. Аяз.** Онытмабыз һәрбер сүзең
Үзәкне өзеп әйткән.
Өметләреңне акларбыз,
Ышандырып ант итәм!
**Зур рәхмәт сиңа, апа, мең рәхмәт!**
**Безнең мәктәптә укуы рәхәт!**

Гыйнвар аенда туучы кадерле укытучыларыбыз:

**Әхмәтова Рузилә Әсхат кызы, Замалеев Айрат Каим улы, Абдрахманов Рәис Азат улы!**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!







Гыйнвар аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Хәлиуллин Инсаф, Стадник Динара, Садртдинов Айдар, Абдрахманова Рәзилә, Хайбуллин Айдар, Закиров Илназ, Шарапова Ләйсән!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хайбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Юнусова Виктория, Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова А.лсинә, Ахметова Нәзилә.